# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.5 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 3.5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, №11; 2009, № 2, № 7-8 (I өлеш), № 9-10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1-2; Ватаным Татарстан, 2010, 31 март; 2 апрель), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"3.5 статья. **Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу**

Элмә такталарны, белдерүләрне, листовкаларны һәм башка тышкы мәгълүматны шул максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда урнаштырган, шулай ук тышкы мәгълүматны урнаштыру урыннарын тиешле халәттә тотмаган өчен –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – бер мең сум; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып егерме мең сумга кадәр; юридик затларга унбиш меңнән алып егерме биш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Шул ук гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

гражданнарга – ике мең биш йөз сумнан алып өч мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга илле меңнән алып йөз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның I июле
№ 44- ТРЗ